**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 2 март № 125

г. Казань

2017 елга социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендәге торакның бер квадрат метр гомуми мәйданы кыйммәтен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасы турында» 2013 ел, 15 июль, 598 нче карары белән расланган «2014 – 2017 елларга һәм 2020 елга кадәрге чорга авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» федераль максатчан программасына 4 нче кушымтаның 13 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Авыл җирендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына, шул исәптән авылда яшәүче һәм эшләүче яисә авыл җиренә даими яшәр өчен күченергә һәм анда эшләргә теләк белдергән яшь гаиләләргә һәм яшь белгечләргә торак төзүгә (сатып алуга) социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендәге торакның бер квадрат метр гомуми мәйданы кыйммәтен 2017 елга 24,3 мең сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\125.doc